КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 25 декабрь г.Казань № 1688

2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә объектлар төзү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы «Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан яңа төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять устав капиталында өлешне түләү чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән 2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә объектлар төзү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы «Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан яңа төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять устав капиталында өлешне түләү чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 25 декабрь, 1688 нче
карары белән расланды

2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә объектлар төзү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы «Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан яңа төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять устав капиталында өлешне түләү чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне, юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук физик затларга - товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә, һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының үз көчләрен югалтуын тану турында гомуми таләпләр хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм 2023 елда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчалары исәбеннән «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесенә (алга таба - предприятие) Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә объектлар төзү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы «Татлизинг» дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан яңа төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять устав капиталында өлешне түләү чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр (алга таба - субсидия) бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешенә аны «Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында» 1998 елның 8 февралендәге 14-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гамәлгә куйганда җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталындагы өлеш өчен түләү керә.

3. Субсидия бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча,

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

4. Субсидия бирү турында килешү (алга таба - килешү) төзү планлаштырыла торган айның 1 числосына предприятие түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру (предприятиегә башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында түгел, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәсә, предприятенең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.

5. Субсидия алу өчен предприятие Министрлыкка 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Дзержинский урамы, 10 йорт адресы буенча шәхси ысул белән яисә почта аша кәгазьдә, түбәндәге документларны теркәп, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча гариза (алга таба - гариза) бирә:

предприятиенең гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турындагы документларның, предприятие җитәкчесе яисә, тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәләрен кушып);

Федераль салым хезмәтенең «Салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айның 1 нче көненә салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе;

предприятие җитәкчесе кул куйган һәм предприятиенең мөһере сугылган, аның бу Тәртипнең 4 пункты таләпләренә туры килүен раслый торган ышаныч хаты.

предприятие тарафыннан яңадан төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьне гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турындагы документларның, предприятие тарафыннан яңадан төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять җитәкчесе яисә, тиешенчә рәсмиләштерелгән вәкаләтләр булганда, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган күчермәләре (Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазенең күчермәләрен кушып).

предприятие әлеге пунктның өченче абзацында каралган документны тапшырмаган очракта, Министрлык күрсәтелгән документны салым органында ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

6. Министрлык заявканы теркәлгән документлары белән кабул итүне һәм кергән көнендә теркәүне гамәлгә ашыра.

Министрлык заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә предприятиене, шулай ук ул тапшырган документларны әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү предметына тикшерә, субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, предприятиенең электрон адресына кабул ителгән карар турында хәбәр җибәрә, ә субсидия бирү турында карар кабул ителгән очракта - Килешү проектын теркәп.

7. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

Предприятиенең бу Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

предприятие тарафыннан тапшырылган документларның бу Тәртипнең 5 пунктында каралган таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

предприятие тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

8. Субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә.

9. Субсидия бирү Министрлык белән субсидия алучы арасында төзелә торган килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелә.

10. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләре, субсидияне күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, шулай ук, кирәк булганда, өстәмә хисап бирү хакында хисап бирү сроклары һәм рәвешләре;

субсидия алучының, субсидия алучы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

бу Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, Килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча Килешүгә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында, субсидияне Килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган шарт.

субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган өчен җаваплылык чаралары;

субсидияләр алучылар, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акчалар алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган чит ил валютасы акчалары исәбеннән, югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, акчалар алуны тыю турында нигезләмәләр;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр.

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучы белән Татарст ан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә Килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

11. Субсидия алучы эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә Килешү проекты аның электрон почтасы адресына илтеп җиткерелгән көннән аңа кул куя һәм Министрлыкка кәгазь рәвештә тапшыра.

12. Субсидия бирү нәтиҗәсе - яңа төзелгән җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталында предприятие өлешен 100 процент түләү. Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү срогы - 2023 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

13. Субсидия күчерү Министрлык тарафыннан килешү төзегән көннең 10 эш көненнән дә соңга калмыйча Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмасы учреждениесендә субсидияләр алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетына гамәлгә ашырыла.

14. Субсидия алучы субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында һәм финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүләрнең бертип рәвешләрендә 2024 елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча хисап тапшыра.

Кирәк булганда Министрлык килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгели.

15. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү шартларын һәм тәртибен, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, үтәвен тикшерә. Дәүләт финанс контроле органнары субсидия алучы тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерә.

16. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган һәм субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшырылмаган очракларда;

Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсеннән тайпылуга пропорциональ рәвештә билгеләнә торган күләмдә – субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәгән очракта.

17. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 16 пунктында билгеләнгән субсидияне ирекле кире кайтару срогы бозылган очракта, Министрлык әлеге срок тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

33. Бирелә торган субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.